ГЛАВА
БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422640, Олы Елга,
Октябрь урамы, 25 йорт

Тел.: (84361) 25-264, факс: (84361) 25-265, эл.адрес: Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

2020 елның 5 ноябре, Олы Елга авылы　　　　　　　　№ 1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга һәм Сорочьи Горы авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 17 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Сорочьи Горы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта көн итүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга, Казаклар, Сорочьи Горы, Кама поселогы авыл торак

пунктлары территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә торып укучы студентлардан,1 төркем инвалидлардан гайре, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга Сез ризамы?

- Олы Елга, Сорочьи Горы авылларындагы су этем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
- авыл җирлеге торак пунктларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга(шартнамә буенча эшкә түләүгә);
- Олы Елга авылында Мөхәммәтгали урамындагы юлларны ремонтлауга (асфальт грануляты сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә, эшләр өчен түләүгә);
-Казаклар авылында Яр буе урамында (вак таш сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, вак ташны җәюгә, эш өчен түләүгә);
-Сорочьи Горы авылының Прикамская, Пролетарская, Садовая-1,Садовая-2 урамнарында(асфальт гранулята сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә , эшләр өчен түләүгә);
-авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап торуга(кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);
- Казаклар авылында  Тау урамындагы инеш аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);
- Олы Елга авылы зираты территориясен  киртәләүгә (тотып алуга) (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);
- Олы Елга авылындагы Яшьләр урамында тышкы суүткәргеч салуга (220 см тирәнлектә траншея казуга, 63 мм диаметрлы торбаларны сузуга, траншеяны күмүгә, янгын гидранты урнаштыруга);
-Казаклар авылында контейнер мәйданчыклары  ясауга һәм җиһазландыруга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);
- Казаклар авылында каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен 5 данә контейнер сатып алуга.

“ЯКЛАП” “КАРШЫ”.

6.Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

7.Карар игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев